# *Гарипова Флюра Фәиз кызы*

*Мин, Гарипова Флюра Фәиз кызы, 1939 нчы елның 25 нче сентябрендә Зур Битаман авылында туып үстем. Сугышка әти белән олы абыем китте, аларга кире әйләнеп кайтырга насыйп булмаган шул. Әтинең "хәбәрсез югалган" дигән хаты килде, ә абый Псков өлкәсендә җирләнгән. Абыем 1924 елгы, аның "Сугышка кирәбез" дигән хаты булган. Минем абыйның буе озын иде, шуңа күрә ул хатында "мин алда барам, иң беренче булып мина атарлар инде" дигән хат җибәрде дип сөйләде апам. Менә шулай, үлеп калган ул.*

*Сугыш башланган вакытта, мин бишектәге бала булып калганмын. Әти киткәндә, миңа кулындагы перәннеген тоттырып киткән. Шулай итеп, сугыш башланганны белүче бала түгел мин. Ул елларда, әнием белән апаем фермада эшләгәннәр, алар безне туендырганнар. Сыерын да сауганнар, тавыклар да асраганнар, дуңгызын да караганнар. Сыер асрадык, шул сыерның маен гөбеләр белән атлап, майны йомарлап, Дөбьяз базарына алып барып сата торган идек. Мин белә башлаганда инде, майдан чыккан суны гына ашадык. Аннары язга чыккач, күкәрин була торган иде инде. Ул черегән бәрәңгене җыеп, келәт идәненә таратып, кипкәч, чистартып, ваклап төеп, коймак пешереп ашый идек. Менә шундый әчлек заманында яшәгән инде. Аннары, басуда башак җыйдык.*



*Укытучыбыз Сафия апа басуга, чиләк, кайчы тоттырып башак җыярга алып чыга иде безне. Бер башакны да калдырмыйча тапшыра идек. Хәзер генә ул, ничек күп итеп кала. Ә ул вакытта бик кадерле булган инде ул. Шулай ук борчакны да җыеп тапшыра идек, басудан кайтканда, тук булып кайта идек инде анысы. Менә шундый заманнарда яшәргә туры килде инде.*

*Мин 7 ел Битаман мәктәбендә укыдым, аннары Алатның урта мәктәбендә 10 сыйныф бетердем. Аннан соң Коопиративный техникумга укырга кердем. Укыганда атна буена 1 ипине берәр сыныклап ашый идек. Марҗа әбиендә тордык, ул әбинең бүлмәсе кечкенә иде инде, бер кечкенә чуенга бәрәңге әрчеп пешерә идек. Бәрәңгене өйдән алып килеп куйганбыздыр инде! Татарчадан урысчага укыгач, бик авыр иде шул. Ул чакта "плюс, минус" ның да нәрсә икәнен дә белмибез. Әни үлгәчтен тагын да авыр булды, иптәшләр арасында да ярдәм юк. Әтисез кешегә болай да бик читен. Ә аннары гомер буе, Битаманда сельпода эшләдем. 40 елдан артык эш стажым бар. Анда эшләгән вакытта күп грамоталар, рәхмәт кәгазьләре алдым. Прафсоюз председателе булып эшләдем, менә шуннан соң 1986 нчы елда "Хезмәт ветераны" таныклыгы алдым. 1997 елда эштән чыктым.*

*Хәзерге яшь буыннар рәхәттә яшиләр, нишләсәләр дә үзләреннән тора. Үзләре укуда да, эштә дә тырышсыннар. Кеше булсыннар, бәхетле булсыннар.*